| | |
|---|---|
| **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТСПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 36 « 11 » июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт хакы өчен факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматларны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматларны бастырып чыгару тәртибен раслау (кушымта итеп бирелә).

Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы
Болгар шәһәре Башкарма комитеты
җитәкче вазыйфаларын башкаручы И. А. Кузнецов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Болгар шәһәр Башкарма комитетының
2020 елның __11__ июненнән № __36__ карарына
1 нче кушымта ____

# Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматларны бастырып чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт хакы өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал мәгълүматларын бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, «Болгар шәһәре»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт хакы өчен факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматларны тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба—белешмәләр).

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Мәгълүматлар муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген башкаручы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны, шулай ук хисап чорында хезмәт өчен түләү чыгымнарын (акчалата тоту) исәпкә алмыйча, хезмәткә түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләме турында квартал саен мәгълүматны (арта бара торган нәтиҗә белән) чагылдыралар.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Болгар шәһәр Башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Болгар шәһәр Башкарма комитеты, хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, Болгар шәһәр Башкарма комитетының мәгълүматларны раслау турындагы карары проекты әзерләнә.

3.2 Болгар шәһәр Башкарма комитеты карары белән расланган хисаптан соң килүче икенче айның соңгы числосына кадәр белешмәләр Болгар шәһәр Башкарма комитеты сайтында басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен бирелә торган
белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

"Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен хисап чорының________________20___елгы түләүгә факттагы чыгымнар турындагы белешмәләр (беренче квартал, яртыеллык, тугыз ай, бер ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | Хисап чорында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы " Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |